**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

04 нче декабрь 2023 ел № 4

"Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, "Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында" 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 нче елның 04 нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу һәм салу, су агымы торбаларын урнаштыру, юлларны кардан грейдировкалау һәм чистарту);
- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (шул исәптән төзелеш материаллары сатып алу);
- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (шул исәптән җәйге вакытта территорияне кисү, трактор өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- **ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (шул исәптән зират территориясен чистарту һәм җыештыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 58 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 30 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 30 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге составына керүче Даныш авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу һәм салу, су агымы торбаларын урнаштыру, юлларны кардан грейдировкалау һәм чистарту);
- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (шул исәптән төзелеш материаллары сатып алу);
- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (шул исәптән җәйге вакытта территорияне кисү, трактор өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- **ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (шул исәптән зират территориясен чистарту һәм җыештыру)” карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 10(ун) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы КамаТамагы
муниципаль районы Олы Салтык
авыл җирлеге башлыгы: Р.М. Вафин